**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**30.12.2022 ел** **№ 1207**

**Үзәктән – Биектау т/юл ст. посёлогыннан 11 километрдан ераграк урнашкан Биектау муниципаль районының ерактагы һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Үзәктән – Биектау т/юл ст. посёлогыннан 11 километрдан ераграк урнашкан Биектау муниципаль районының ерактагы һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 2583 номерлы (04.05.2020 №595, 16.05.2022 №491, 21.10.2022 №1011 карарлары редакциясендә) карары белән расланган Үзәктән – Биектау т/юл ст. посёлогыннан 11 километрдан ераграк урнашкан Биектау муниципаль районының ерактагы һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.1. Субсидияләр алучыларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, тикшерү, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268 һәм 2692 статьялары нигезендә Биектау муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан тикшерү гамәлгә ашырыла.»
2) түбәндәге эчтәлекле 2.1.2 пунктны өстәргә:
«2.1.2. Субсидияләр биргәндә, аларны бирүне җайга сала торган субсидияләр бирү турындагы шартнамәләргә (килешүләргә) һәм (яисә) норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге шартнамәләр (килешүләр) буенча

йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) кертелә торган аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидияләр алучыларның һәм товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләре һәм (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашкан җәмгыятьләрдән шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерция оешмаларынан тыш) бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсдияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча җиткерүчеләр (подрядчиклар, башкаручылар) булган затларның субсидия бирә торган бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) тарафыннан һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган тикшерүләрне дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары гамәлгә ашыруга ризалыгы тора.».

3) 4 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторингны) гамәлгә ашыру».

2. Тәртип 2023 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин